РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 1 сентябре 315№

Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын, шул исәптән адаптив төп гомуми белем бирү программалары гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләргә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2020 елның 15 гыйнварындагы Юлламасын гамәлгә ашыру буенча 2020 елның 24 гыйнварындагы Пр-113 номерлы йөкләмәләр исемлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 декабрендәге «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында»гы 1642 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын, шул исәптән адаптив төп гомуми белем бирү программалары гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләргә 2020 елның 1 сентябреннән сыйныф җитәкчелеге өчен аена 5000 сум күләмендә айлык акчалата түләү (алга таба-бүләкләү, гомуми белем бирү оешмалары) билгеләргә.

2. Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын, шул исәптән адаптив төп гомуми белем бирү программалары гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләргә сыйныф

җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү билгеләү турындагы Нигезләмәне расларга.

3. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә акча түләүгә бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетыннан Әлки муниципаль районы бюджетына бүлеп бирелгән субвенция акчалары исәбеннән финанслау гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Әлки районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Юсупов

Расланган
ТР Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның ____ ______________
_____№ Карары

Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын, шул исәптән адаптив төп гомуми белем бирү программалары гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләргә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү билгеләү турындагы Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары гамәлгә ашыра торган педагогик хезмәткәрләргә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләүне (алга таба - бүләкләү, гомуми белем бирү оешмалары) билгеләү, түләү һәм туктату шартларын билгели.

2. Бүләкләү гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән адаптив гомуми белем бирү программаларын тормышка ашырыла торган педагогик хезмәткәргә сыйныфта (сыйныфларда), шулай ук һәр сыйныфның укучылары санына бәйсез рәвештә бер сыйныф дип кабул ителә торган сыйныф-комплектта (алга таба - сыйныф) сыйныф җитәкчелеге өчен түләнә.

3. Сыйныф җитәкчелеген ике һәм аннан да күбрәк сыйныфларда гамәлгә ашыручы педагог хезмәткәргә акчалата түләүнең икеләтә түләве ( әмма, икедән артык түгел) билгеләнергә мөмкин.

4. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең сыйныф җитәкчесе функцияләрен йөкләү турындагы боерыгы педагогик хезмәткәргә бүләкләү билгеләү өчен нигез булып тора.

5. Гомуми белем бирү оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәрләргә сыйныф җитәкчелеге өчен акчалата түләү йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, өч яшькә җиткәнче бала карау ялы чорына туктатыла.

6. Сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкаручы педагогик хезмәткәрне бүләкләү күләме педагогик йөкләнеше күләменә бәйле түгел.

7. Бүләкләү уртача хезмәт хакы исәбенә кертелә.

8. Педагогик хезмәткәрләргә бүләкләү хезмәт хакы белән бер үк вакытта түләнә.

9. Уку елы дәвамында, каникуллар чорында, шулай ук санитар-эпидемиологик, климатик һәм башка нигезләр буенча белем бирүче дәресләр өчен туктатылу (булмау) чорында, педагогик хезмәткәр гаебе белән сыйныф җитәкчелеге буенча эшләмәү яки тиешенчә башкармау очракларыннан тыш, педагогик хезмәткәрләргә түләүнең күләмен үзгәртү яисә түләүне гамәлдән чыгару рөхсәт ителми.

10. Мәгариф оешмасы җитәкчесе боерыгы педагогик хезмәткәргә бүләкләүне туктату һәм гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора.